КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 12 май г.Казань № 695

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен алу турында

Россия Федерациясе Җир кодексының 49 статьясы, VII[1] бүлеге, Россия Федерациясе Граждан кодексының 279 һәм 281 статьялары, Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2011 ел, 21 февраль, 134 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстан юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенең (алга таба – Татарстанның юл-транспорт идарәсе) Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында М-12 «Восток» трассасыннан алып Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы һәм Татарстан Республикасы Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә «Казан – Оренбург – Акбулак – Казахстан Республикасы чиге» 1 нче өстәмә этап» автомобиль юлына кадәр автомобиль юлларын төзү һәм реконструкцияләү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен 752 869 кв.метр гомуми мәйданлы җир кишәрлекләреннән барлыкка килгән, кушымтада күрсәтелгән 21 151 кв.метр гомуми мәйданлы җир кишәрлекләрен (алга таба – алына торган җир кишәрлекләре) алу турындагы тәкъдимен кабул итәргә. Алына торган җир кишәрлекләре юридик һәм физик затлар (алга таба – алына торган җир кишәрлекләре милекчесе) милкендә тора.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында М-12 «Восток» трассасыннан «Казан – Оренбург – Акбулак – Казахстан Республикасы чиге» автомобиль юлына кадәр (1 нче өстәмә этап) автомобиль юлларын төзүне һәм реконструкцияләүне тәэмин итү өчен кирәкле төзелеш материалларын һәм башка материалларны бер урынга туплау, капиталь булмаган төзелмәләр, корылмалар

(коймаларны, бытовкаларны, япмаларны кертеп) кору һәм төзелеш техникасын урнаштыру максатларында гавами сервитут билгеләү турында» 2025 ел, 7 октябрь, 807 нче карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Атабай торак пунктына Д325 мм югары басымлы җир асты газүткәргече» газ белән тәэмин итү системасының төбәк әһәмиятендәге линия объектын урнаштыру (реконструкцияләп, алга таба эксплуатацияләү) максатларында «Газстройпром» акционерлык җәмгыяте мәнфәгатьләрендә гавами сервитут билгеләү турында» 2021 ел, 13 декабрь, 1218 нче карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Миңлебай – Казан» магистраль этанүткәргеч» газ белән тәэмин итү системасының линия объектын эксплуатацияләү максатларында гавами сервитут урнаштыру турында» 2025 ел, 20 ноябрь, 974 нче карары нигезендә алына торган җир кишәрлекләренә карата билгеләнгән гавами сервитутлар саклана.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына түбәндәгеләрне законнар белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә:

3.1. 10 көн эчендә:

бу карарны үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

бу карарны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының һәм Татарстан Республикасы Казан шәһәренең муниципаль хокукый актларын рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгаруны;

бу карарның күчермәләрен алына торган җир кишәрлекләре милекчеләренә, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, Татарстанның юл-транспорт идарәсенә җибәрүне.

3.2. Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен алу турында килешүләр (алга таба – килешүләр) төзүне.

3.3. Алына торган җир кишәрлекләре өчен түләүләр түләүне.

4. Татарстанның юл-транспорт идарәсенә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Лаеш муниципаль районы һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә «Татарстан Республикасының Лаеш муниципаль районындагы М-12 «Восток» трассасыннан Казан – Оренбург – Акбулак – Казахстан Республикасы белән чик автомобиль юлына кадәр автомобиль юлларын төзү һәм реконструкцияләү» 1 нче өстәмә этап» линия объектын урнаштыру карала торган территорияне планлаштыру проектын һәм территорияне межалау проектын раслау турында» 2025 ел, 30 июль, 557 нче карары белән расланган территорияне планлаштыру һәм межалау проектлары нигезендә 16:24:050802:3239, 16:24:050802:4235, 16:24:150305:3906, 16:24:150305:14, 16:24:150201:2793, 16:24:150302:2042, 16:24:150302:6942, 16:24:000000:6079 кадастр номерлы алына торган җишәрлекләренә карата кадастр эшләрен башкаруны;

Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә алына торган җир кишәрлекләре өчен түләүләр күләмен билгеләүне;

алына торган җир кишәрлекләре өчен түләүләр күләме билгеләнгәннән соң 30 көн эчендә килешүләр әзерләүне һәм аларны алына торган җир кишәрлекләре милекчеләренә җибәрүне;

алына торган җир кишәрлекләре милекчеләре тарафыннан имза куелган килешүләр законнар белән билгеләнгән срокта тапшырылмаган очракта, судка тиешле дәгъвалар бирүне.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2026 ел, 12 май, 695 нче
карарына кушымта

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен алынырга тиешле
җир кишәрлекләре исемлеге

| Кадастр номеры | Урнашу урыны | Мәйданы, кв.метр | Алына торган мәйдан, кв.метр | Милекчесе |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 16:24:150302:1106 | Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Столбище авыл җирлеге, Усад авылы | 175 | 175 | «Сувар-Казань» акционерлык җәмгыяте |
| 16:24:150302:1113 | Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Столбище авыл җирлеге, Усад авылы | 335 | 335 | «Сувар-Казань» акционерлык җәмгыяте |
| 16:24:150302:1368 | Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Столбище авыл җирлеге, Усад авылы | 222 | 222 | «Сувар-Казань» акционерлык җәмгыяте |
| 16:24:050802:3239 | Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Никольский авыл җирлеге | 40 872 | 11 521 | Андреева Минсира Миначт-диновна |
| 16:24:050802:4235 | Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Никольский авыл җирлеге | 12 616 | 264 | Мартынов Владимир Викто-рович |
| 16:24:150305:3906 | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Усад авылыннан төньяк-көнчыгышка таба 500 м ераклыкта | 638 238 | 6 283<br>1 053 | «Базис-Терра» акционерлык җәмгыяте |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 16:24:150305:14 | Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы | 5 000 | 38 | «ШЕЛЛ НЕФТЬ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгы-яте |
| 16:24:150201:2793 | Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Столбище авыл җирлеге, Усад авылы | 12 000 | 682 | «Консолидация» ябык пайлы инвестиция катнаш фонды |
| 16:24:150302:2042 | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре | 7 699 | 260 | «Жилищный капитал» ябык пай инвестиция катнаш фонды |
| 16:24:150302:6942 | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре | 12 393 | 229 | «Сувар-Казань» акционерлык җәмгыяте |
| 16:24:000000:6079 | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре | 23 319 | 89 | «Базис-Терра» акционерлык җәмгыяте |
| Барлыгы | | 752 869 | 21 151 | |

___